ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423714 Республика Татарстан, Мензелинский район, с.Наратлы-Кичу, ул.Центральная, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРАТЛЫ-КИЧУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423714 Татарстан Республиксы, Минзәлә районы, Наратлы-Кичү авылы, Центральный урамы, 2

# КАРАР

№ 2 07.02.2024г.

2024-2028 елларга электрон рәвештә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык китапларын нигезләү һәм алып бару турында

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2023 елның 07 июлендәге №112-ФЗ Федераль законның 8 статьясы, «Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Хуҗалык китапларын алып бару рәвешләрен һәм тәртибен раслау турында» 27.09.2022 №629 боерыгы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Наратлы-Кичү авыл җирлеге »муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык китапларын, 2024-2028 елларга, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисаплылыгын җыюның һәм эшкәртүнең комплекслы мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон формада, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең җыелма хисапларын формалаштыру, агросәнәгать комплексына субсидияләр мониторингы, исәпкә алу, тикшереп тору һәм анализлау буенча яңа хуҗалык китабын нигезләүне оештырырга.

2. Ел саен, 1 гыйнварга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тулысынча урап узу һәм шәхси ярдәмче хуҗалык әгъзаларыннан (алга таба - ШЯХ) сораштыру юлы белән 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр китапларда күрсәтелгән мәгълүматларны җыюны гамәлгә ашырырга.
ШЯХ турында китапта белешмәләр эчтәлеге шәхси ярдәмче хуҗалыклар турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткәндә башка даталарга аларның инициативасы буенча төгәлләштерелергә мөмкин.

3. Хуҗалык китапларына язмаларны үз ихтыяры белән шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яисә шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә теркәргә.

4. Хуҗалык китапларын алып барганда, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны алып бару өчен рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлеге бирелгән һәм (яисә) сатып алынган гражданнар тарафыннан бирелгән мәгълүматның конфиденциальлеген, аның сакланышын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклануын тәэмин итәргә кирәк.

5. Электрон хуҗалык китапларын билгеләнгән тәртиптә алып бару һәм аларның саклануы өчен җаваплы итеп белгечне - Шәрәфиева Л.М. билгеләргә.

6. Әлеге карарны Наратлы-Кичү авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

8. Карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, 33 пунктның 2 абзацыннан, шулай ук 2024 елның 1 февраленнән үз көченә кергән хуҗалык китапларын алып бару тәртибенең 36 пунктыннан тыш.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.М.Вәлиев